Республика Татарстан
Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге

КАРАР
14.12.2023 ел

КАРАР
№90

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2024 нче елга һәм 2025, 2026 нче еллар план чорына бюджеты турында

“Россия Федерациясенлә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Иске Имән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Иске Имән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Статья 1

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2024 нче елга бюджетының төп характеристикасын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 3 761,0 мең сум күләмендә;
2) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 3 761,0 мең сум;
3) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум.

2.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2025 нче елга һәм 2026 нче елга бюджетының төп характеристиксын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2025 нче елга фаразланган кеременең гомуми күләме 3 882,2 мең сум һәм 2026 нчы елга 4 003,2 мең сум күләмендә;

2) 2025 нче елга гомуми чыгымнары күләме 3 882,2 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 97,0 мең сум күләменлә, һәм 2026 нчы елга 4 003,2 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвешә расланган чыгымнар 200,0 мең сум күләмендә.
3) Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2025 нче елга 0,0 мең сум һәм 2026 нчы елга 0,0 мең сум.

3.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2024 нче елга һәм 2025, 2026 нчы еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 2

1.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2025 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычының югары чиген Россия Федерациясе валютасында нульле итеп расларга.

2.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2026 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычының югары чиген Россия Федерациясе валютасында нульле итеп расларга.

3.Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2026 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча буычының югары чиген Россия Федерациясе валютасында нульле итеп расларга.

Статья 3

Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетында 2024 нче елга һәм 2025, 2026 нче еллар план чорына фаразланган керем күләмен карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

Статья 4

1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының 2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына чыгымнарының ведомство структурасын шушы карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалары һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), 2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарның 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль программалары һәм программага карамаган эшчәнлек

юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, 2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарның 5 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2024 нче елга 0,0 мең сум, 2025 нче елга 0,0 мең сум, 2026 нче елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

Статья 5

1.Иске Имән авыл җирлеге бюджетының 2024 нче елга, төзелгән килешүләр нигезендә, мәдәният хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү буенча шартлар тудыру буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен 1 827,6 мең сум, 2024 нче елга 1 855,7 мең сум, 2025 нче елга 1 885,8 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга.
2. 2024 нче елда Иске Имән авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны күчерү квартал саен башкарыла дип билгеләргә.

Статья 6

Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетында Сарман муниципаль районы бюджетыннан алына торган акчаны исәпкә алырга:
1)2024 нче елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр – 2 859,8 мең сум, 2025 нче елга – 2 968,3 мең сум, 2026 нчы елга – 3062,8 мең сум;
2) 2024 нче елга территорияләрендә хәрби коммисариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен башкаруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр – 152,5 мең сум, 2025 нче елга – 167,9 мең сум, 2026 нче елга- 184,0 мең сум.

Статья 7

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль казна учреждениеләре яңа функцияләр яисә вәкаләтләр, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына бирү белән бәйле мондый карарлар кабул итү очракларыннан тыш Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2024 нче елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль учреждение хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Статья 8

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге бюджеты акчалары калдыклары 2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге исеменнән 2023 елда товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактлар өчен

тотылганнар өчен түләүгә кулланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләрен арттыруга 2024 елда җибәрелә.

Статья 9

Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгының казначылык органнары төзелгән киешүләр нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

Статья 10

Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO TATARSTAN. RU) һәм Татарстан Республикасы “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

Статья 11

Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан көченә керә.

Статья 12

Әлеге карарның үтәлеше контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге Советы рәисе: Р.Ә.Исламова